**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Әлкәй авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

Әлкәй авылы № 134 «27» ноябрь 2024 ел

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әлкәй авыл җирлеге Советының 2014 елның 11 ноябрендәге 97 номерлы «Физик затлар мөлкәтенә салым турында»гы карарына үзгәрешләр кертү хакында (14.08.2015 №120, 29.10.2015 №13, 24.04.2018 №93, 15.11.2018 №116, 24.12.2018 №121, 24.06.2019 №139, 11.11.2019 №153, 15.03.2021 №21карарлар редакциясендә)

«Россия Федерациясе Салым кодексының беренче һәм икенче өлешләренә, Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясе закон актларының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану турында»гы 2024 елның 12 июлендәге 176-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә

Әлкәй авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әлкәй авыл җирлеге Советының 2014 елның 11 ноябрендәге 97 номерлы «Физик затлар мөлкәтенә салым турында»гы карарына (14.08.2015 №120, 29.10.2015 №13, 24.04.2018 №93, 15.11.2018 №116, 24.12.2018 №121, 24.06.2019 №139, 11.11.2019 №153, 15.03.2021 №21карарлар редакциясендә) түбәндәнге үзгәрешләрне кертергә:
1.1. 2 пунктның 4 пунктчасын яңа редакциядә бәян итәргә:
«4) - Россия Федерациясе Салым кодексының 378.2 статьясындагы 10 пунктының икенче абзацында каралган салым салу объектларына карата Россия Федерациясе Салым кодексының 378.2 статьясындагы 7 пункты нигезендә билгеләнә торган исемлеккә кертелгән салым салу объектларына карата 2025-2027 елларга күчеш чорына 1,2 процент;

-Һәркайсының кадастр бәясе 300 миллион сумнан артып киткән, салым салу объектларына карата 2025-2027 елларга күчеш чорына 2 процент.
Әлеге карарның 2 статьясындагы 4 пунктында күрсәтелгән күчеш чорлары узганнан соң физик затлар мөлкәтенә салым ставкалары Россия Федерациясе Салым кодексының 406 статьясындагы 2 пунктының 2 һәм 2.1 пунктчалары нигезендә билгеләнә.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет "мәгълүмат-коммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча» урнаштырырга: http://aznakaevo.tatar.ru.

3. Әлеге карар 2025 елның 1 гыйнварыннан, әмма массакүләм мәгълүмат чараларында рәсми басылып чыккан көненнән кимендә бер ай узгач үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны бюджет, финанс, салымнар һәм икътисад буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Рәис С.З.Зиннурова